КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2025 ел, 20 март г.Казань № 161

Татарстан Республикасы халкына психологик ярдәм күрсәтү системасының ведомствоара эксперт советы турында

Татарстан Республикасы халкына психологик ярдәм күрсәтү системасын үстерү һәм ведомствоара хезмәттәшлекне көчәйтү максатларында Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Түбәндәгеләрне (карарга теркәләләр) расларга:

Татарстан Республикасы халкына психологик ярдәм күрсәтү системасының ведомствоара эксперт советы турындагы нигезләмәне;

Татарстан Республикасы халкына психологик ярдәм күрсәтү системасының ведомствоара эксперт советы составын.

2. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасы Яшьләр эшләре министрлыгына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2025 ел, 20 март, 161 нче карары белән расланды

# Татарстан Республикасы халкына психологик ярдәм күрсәтү системасының ведомствоара эксперт советы турында нигезләмә

## I. Гомуми нигезләмәләр

1.1. Татарстан Республикасы халкына психологик ярдәм күрсәтү системасының ведомствоара эксперт советы (алга таба – Эксперт советы) Татарстан Республикасы халкына психологик ярдәм күрсәтү системасының нәтиҗәлелеген күтәрү һәм психологның һөнәри статусын яклау өчен булдырылган даими эшләүче киңәшмә орган булып тора.

1.2. Эксперт советы үз эшчәнлегендә федераль законнарга, Татарстан Республикасы законнарына һәм әлеге Нигезләмәгә таянып эш итә.

## 2. Эксперт советының максатлары, бурычлары һәм функцияләре

2.1. Эксперт советының максаты – Татарстан Республикасы халкына психологик ярдәм күрсәтү системасының нәтиҗәлелеген күтәрү.

2.2. Эксперт советы бурычлары:

Татарстан Республикасы халкына психологик ярдәм күрсәтүнең сыйфатын яхшыртуда һәм аннан файдалануны арттыруда ярдәм итү;

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан расланган Татарстан Республикасы халкына психологик ярдәм күрсәтү системасын үстерү концепциясен гамәлгә ашыру чаралары планын булдыру һәм актуальләштерү;

Татарстан Республикасы психологларының һөнәри ведомствоара эшчәнлегендә методологик һәм концептуаль алымнарны килештерү.

2.3. Эксперт советы түбәндәге функцияләрне башкара:

психология өлкәсендә фәнни, аналитик, программа, методик эшләнмәләрне, эксперименталь һәм инновацион эшчәнлекне, технологик инструментарийны экспертизалауга алымнарны, шулай ук Татарстан Республикасы халкына психологик ярдәм күрсәтү системасын камилләштерү мәсьәләләре буенча, шул исәптән психологлар әзерләү буенча тәкъдимнәрне билгеләү;

Татарстан Республикасы халкына психологик ярдәм күрсәтү системасындагы психологларның һөнәри хокукларын һәм мәнфәгатьләрен яклау;

Татарстан Республикасы халкына психологик ярдәм күрсәтү системасы психологлары эшендә, алга таба Россия психологлар берләшмәсенә интеграцияләү өчен, аларның һөнәри культурасын һәм квалификация дәрәҗәсен арттыру буенча тәкъдимнәр кертү.

## 3. Эксперт советының составы һәм эшен оештыру

3.1. Эксперт советы составы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары белән раслана.

3.2. Эксперт советы составы тармакның (өлкәнең) психологик хезмәтләре өчен җавап бирүче республика хакимият органнары җитәкчеләре урынбасарлары һәм җитәкчеләре, Татарстан Республикасы халкына психологик ярдәм күрсәтү системасы белән эшчәнлеге бәйле булган республика комиссияләре һәм иҗтимагый оешмалар җитәкчеләре урынбасарлары һәм җитәкчеләре, шулай ук психология өлкәсендә эшләүче галимнәр һәм практиклар саныннан төзелә.

3.3. Эксперт советы Эксперт советы рәисе, аның ике урынбасары, секретаре һәм әгъзалары составында төзелә.

3.4. Эксперт советы рәисе, аның урынбасарлары, Эксперт советы секретаре һәм әгъзалары үз эшчәнлекләрен түләүсез нигездә башкара.

3.5. Эксперт советы рәисе Эксперт советы эшчәнлегенә җитәкчелек итә һәм Эксперт советы утырышларының көн тәртибен раслый.

3.6. Эксперт советы рәисе булмаган очракта, утырышны рәис урынбасары уздыра, ул Эксперт советы рәисе карары белән билгеләнә.

3.7. Эксперт советы секретаре Эксперт советы эшен оештыру ягыннан тәэмин итүне гамәлгә ашыра: Эксперт советы утырышларына материаллар, Эксперт советы чаралары планын төзи, аның эше турында еллык хисап әзерли һәм аны Эксперт советы рәисенә килештерүгә тәкъдим итә.

3.8. Эксперт советы эшчәнлеге Эксперт советы беркетмәсе белән раслана торган Эксперт советы чараларының еллык планы нигезендә гамәлгә ашырыла. Планнан тыш көн тәртипләре буенча барлык тәкъдимнәр Эксперт советы әгъзалары тарафыннан язма рәвештәЭксперт советы секретарена Эксперт советы утырышын уздыру планлаштырылган айга кадәрге айның 10ысыннан да соңга калмыйча тапшырыла.

3.9. Эксперт советы утырышлары кирәк булуга карап, әмма кварталга кимендә бер тапкыр үткәрелә.

3.10. Эксперт советы әгъзаларына Эксперт советы утырышы, аның көн тәртибе һәм уздыру урыны турында Эксперт советы сәркатибе тарафыннан Эксперт советы әгъзаларының электрон почтасына тиешле хәбәрнамә җибәрү юлы белән аны үткәрүгә кимендә өч эш көне кала язма рәвештә хәбәр ителә.

3.11. Эксперт советы эшчәнлеге турыдан-туры яки онлайн утырышлар рәвешендә гамәлгә ашырыла. Эксперт советы утырышлары, әгәр аларда аның составына керүче Эксперт советы әгъзаларының яртысыннан да ким булмаган өлеше катнашса, хокуклы дип санала.

3.12. Эксперт советы карарлары Эксперт советы утырышында катнашучы Эксперт советы әгъзалары саныннан гади күпчелек тавыш бирү белән ачык тавыш биреп кабул ителә. Тавышлар тигез булганда рәислек итүченең тавышы хәлиткеч була.

3.13. Эксперт советы карарлары беркетмә белән рәсмиләштерелә, аңа Эксперт советы утырышы уздырылган көннән алып биш эш көне эчендә рәислек итүче тарафыннан имзалана.

3.14. Эксперт советы беркетмәләре Эксперт советы секретаре тарафыннан Эксперт советы утырышы беркетмәсенә имза куелганнан соң өч эш көне эчендә барлык әгъзаларының электрон почталарына җибәрелә.

## 4. Эксперт советының һәм аның әгъзаларының хокуклары һәм бурычлары

4.1. Эксперт советы түбәндәгеләргә хокуклы:

Татарстан Республикасы һәм Россия Федерациясе халкына психологик ярдәм күрсәтү системасындагы проблемалар турында оешмалар вәкилләренең хәбәрләрен тыңларга;

Эксперт советы утырышының көн тәртибенә Татарстан Республикасы халкына психологик ярдәм күрсәтү системасын камилләштерү буенча тәкъдимнәр белән бәйле мәсьәләләрне кертергә;

Эксперт советы утырышында катнашу өчен фәнни һәм мәгариф оешмалары вәкилләрен чакырырга.

4.2. Эксперт советы әгъзалары түбәндәгеләргә хокуклы:

Эксперт советы эшчәнлеге турында мәгълүмат алырга;

Эксперт советы утырышында булмаган очракта, шулай ук Эксперт советы утырышында кабул ителгән мәсьәләләр буенча үз фикерен белдерү карары белән - килешмәгән очракта, ул язма рәвештә бәян ителә һәм Эксперт советы утырышы беркетмәсенә мәҗбүри рәвештә беркетелергә тиеш.

4.3. Эксперт советы әгъзалары:

Эксперт советы эшчәнлегендә һәм Эксперт советы утырышларында шәхсән катнаша;

Эксперт советы карарларын кабул иткәндә тигез хокукларга ия була;

Эксперт советының һәм аның рәисенең Эксперт советы утырышы беркетмәсендә беркетелгән йөкләмәләрен үти;

Эксперт советы карарларын гамәлгә ашыруга ярдәм күрсәтә.

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2025 ел, 20 март, 161 нче карары белән расланды

Татарстан Республикасы халкына психологик ярдәм күрсәтү системасының ведомствоара эксперт советы составы

| | |
|---|---|
| Фазлыева Ләйлә Ринат кызы | Татарстан Республикасы Премьер-министры урынбасары, Эксперт советы рәисе |
| Садыйков Ринат Наил улы | Татарстан Республикасы яшьләр эшләре министры, Эксперт советы рәисе урынбасары |
| Һадиуллин Илсур Гәрәй улы | Татарстан Республикасы мәгариф һәм фән министры, Эксперт советы рәисе урынбасары |
| Галиева-Мустафина Софья Альфред кызы | Татарстан Республикасы яшьләр эшләре министрының беренче урынбасары, Эксперт советы секретаре |

Эксперт советы әгъзалары:

| | |
|---|---|
| Абашев Әлмир Рәшид улы | Татарстан Республикасы сәламәтлек саклау министрының беренче урынбасары |
| Абдреева Юлия Ивановна | Татарстан Республикасы хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министры урынбасары |
| Әдһәмова Юлия Илдар кызы | Татарстан Республикасы мәдәният министрының беренче урынбасары |
| Әсәдуллина Алсу Мөнип кызы | Татарстан Республикасы мәгариф һәм фән министры урынбасары |
| Атагунов Владислав Илгизәр улы | «Навигатор» яшьләр, инновация һәм профилактика программалары буенча республика үзәге» дәүләт бюджет учреждениесе директоры урынбасары |
| Белоусова Марина Владимировна | Казан дәүләт медицина академиясенең – Россия Федерациясе Сәламәтлек саклау министрлыгының «Россия өзлексез һөнәри белем бирү медицина |

| | |
|---|---|
| | академиясе» өстәмә һөнәри белем бирү федераль дәүләт бюджет мәгариф учреждениесе филиалының психотерапия һәм наркология кафедрасы мөдире (килешү буенча) |
| Вәлиева Әлфия Зәйнулла кызы | «Ватанны саклаучылар» махсус хәрби операциядә катнашучыларга ярдәм күрсәтү дәүләт фондының Татарстан Республикасы буенча филиалы җитәкчесенең медицина ярдәме күрсәтеп тору буенча урынбасары (килешү буенча) |
| Васильев Роман Игоревич | «Росток» психологик-педагогик тернәкләндерү һәм коррекцияләү үзәге» дәүләт автоном мәгариф учреждениесе директоры (килешү буенча) |
| Вахранева Екатерина Вячеславовна | Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгының медицина психологиясе буенча штаттан тыш баш белгече, Казан шәһәренең «М.Н.Садыйков исемендәге 7 нче шәһәр клиник хастаханәсе» дәүләт автоном сәламәтлек саклау учреждениесенең медицина реабилитациясе буенча амбулатория бүлегенең медицина психологы (килешү буенча) |
| Газизова Диләрә Фуат кызы | Россия Федерациясе Гражданнар оборонасы эшләре, гадәттән тыш хәлләр һәм табигый бәла-казалар салган зыяннарны бетерү министрлыгының Татарстан Республикасы буенча баш идарәсенең психологик тәэмин итү бүлеге башлыгы |
| Гәрәев Илдус Халик улы | Татарстан Республикасы Куркынычсызлык Советы эшчәнлеген тәэмин итү бүлеге мөдире, Татарстан Республикасында терроручылыкка каршы комиссия аппараты җитәкчесе (килешү буенча) |
| Гарифуллина Илсөяр Хәләлетдин кызы | Татарстан Республикасы буенча Эчке эшләр министрлыгының Участок вәкаләтле полициясе һәм балигъ булмаганнар эшләре бүлекчәләре эшчәнлеген оештыру идарәсе баш белгече, балигъ булмаганнар эшләре һәм аларның хокукларын яклау буенча республика комиссиясенең җаваплы секретаре (килешү буенча) |

| | |
|---|---|
| Герасимова Вера Вадимовна | Казан дәүләт медицина академиясенең – Россия Федерациясе Сәламәтлек саклау министрлыгының «Россия өзлексез һөнәри белем бирү медицина академиясе» өстәмә һөнәри белем бирү федераль дәүләт бюджет мәгариф учреждениесе филиалының психотерапия һәм наркология кафедрасы доценты (килешү буенча) |
| Горохова Лилия Гигелевна | Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгының медицина психологиясе буенча штаттан тыш баш балалар белгече, «Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгының Республика балалар клиник хастаханәсе» дәүләт автоном сәламәтлек саклау учреждениесенең психологик бүлеге мөдире (килешү буенча) |
| Горшунова Марина Валентиновна | «Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының Республика ресурс үзәге» дәүләт казна учреждениесе директоры (килешү буенча) |
| Гурьянова Татьяна Владимировна | Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгының штаттан тыш баш белгече психиатры, «Академик В.М.Бехтерев исемендәге Республика клиник психиатрия хастаханәсе» дәүләт автоном сәламәтлек саклау учреждениесенең оештыру-методика эше буенча баш табиб урынбасары (килешү буенча) |
| Домолазова Светлана Евгеньевна | «Ашыгыч чакырулар хезмәте – 112» дәүләт бюджет учреждениесенең психологик ярдәм бүлеге башлыгы (килешү буенча) |
| Зарипов Раушан Булат улы | Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты - Аппаратының Сәламәтлек саклау, спорт һәм сәламәт яшәү рәвешен формалаштыру мәсьәләләре идарәсе башлыгы |
| Лундовских Ирина Васильевна | Яр Чаллы шәһәренең «Диалог» балаларга һәм яшьләргә психологик-педагогик ярдәм үзәге» муниципаль бюджет учреждениесе директоры (килешү буенча) |

| | |
|---|---|
| Лушпаева Ирина Игоревна | Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгының мәгариф системасында штаттан тыш баш психолог-эксперты, «Казан (Идел буе) федераль университеты» югары белем бирү федераль дәүләт автоном мәгариф учреждениесенең Психология һәм мәгариф институтына караган педагогик психология кафедрасы мөдире (килешү буенча) |
| Менделевич Владимир Давыдович | Россия Федерациясе Сәламәтлек саклау министрлыгының «Казан дәүләт медицина университеты» югары белем бирү федераль дәүләт бюджет мәгариф учреждениесенең медицина һәм гомуми психология һәм педагогика кафедрасы мөдире (килешү буенча) |
| Мостафаева Альмира Әнәс кызы | Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Аппаратының Сәламәтлек саклау, спорт һәм сәламәт яшәү рәвешен формалаштыру мәсьәләләре идарәсе башлыгы урынбасары |
| Овчинникова Елена Владимировна | Казан шәһәренең «Доверие» балаларга һәм яшьләргә психологик-педагогик ярдәм үзәге» муниципаль бюджет яшьләр сәясәте учреждениесе директоры, Татарстан Республикасы дәүләт яшьләр сәясәте өлкәсе психологларының Республика консультатив-методик советы рәисе (килешү буенча) |
| Парфенова Лариса Анатольевна | «Интеллектуаль бозылышлары булган затларның бөтенроссия спорт федерациясе» гомумроссия иҗтимагый оешмасының Татарстан Республикасындагы төбәк бүлекчәсе рәисе (килешү буенча) |
| Попов Леонид Михайлович | «Казан (Идел буе) федераль университеты» югары белем бирү федераль дәүләт автоном мәгариф учреждениесенең Психология һәм мәгариф институтына караган клиник психология һәм шәхес психологиясе кафедрасы профессоры (килешү буенча) |
| Садриев Илдар Зөфәр улы | Татарстан Республикасы спорт министры урынбасары |
| Фәхретдинова Лилия Раиф кызы | «Казан (Идел буе) федераль университеты» югары белем бирү федераль дәүләт автоном мәгариф учреждениесенең Психология һәм мәгариф институтына караган гомуми психология кафедрасы профессоры |

| | |
|---|---|
| | (килешү буенча) |
| Черепанова Екатерина Владимировна | Җәзаларны үтәтү федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсенең психологик хезмәте башлыгы (килешү буенча) |
| Шәрипова Гүзәл Азат кызы | «Навигатор» яшьләр, инновация һәм профилактика программалары буенча республика үзәге» дәүләт бюджет учреждениесе директоры. |